КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче; 2022 ел, 25 июль, 716 нчы; 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

4.6 пунктның 2 пунктчасындагы җиденче абзацында «2021 – 2022 елларда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның җиденче абзацында «2021 – 2022 елларда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 – 2024 елларда «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан

Республикасы бюджетыннан юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирү тәртибендә:

1.6 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Заявкага оешмалар җитәкчеләренең, индивидуаль эшмәкәрләрнең имзасы һәм мөһер белән таныкланган (булганда) түбәндәге документлар һәм белешмәләр теркәлә:

а) салым органы тарафыннан сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1нче көненә карата Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турында белешмә кәгазе;

б) субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты алдында акчалата йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда), индивидуаль эшмәкәр тарафыннан имза куелган, мөһер белән (булганда) расланган белешмә кәгазе;

в) оешмаларның үзгәртеп оештыру (оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә индивидуаль эшмәкәрләрнең үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавын раслый торган, оешма җитәкчесе, индивидуаль эшмәкәр тарафыннан имза куелган, мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазе;

г) коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затларга яки оешманың баш бухгалтерына (баш бухгалтеры булганда), индивидуаль эшмәкәрләргә Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү тәртибен, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе формаларын раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) соратыла торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе;

д) оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган, оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган, мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазе;

е) оешманың, индивидуаль эшмәкәрнең сайлап алу үткәрелә торган елда әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алучылар булмавын раслый торган, оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда), индивидуаль эшмәкәр тарафыннан имза куелган, мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазе;

ж) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яки физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның (Индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәләре;

з) «Сиделка» хезмәте күрсәтү яки өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү тәҗрибәсенең кимендә бер ел булуын раслый торган, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан декларацияләнгән белешмәләр;

и) Татарстан Республикасында Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән расланган 2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 6.4 пунктында каралган таләпләргә туры килә торган, Татарстан Республикасында «Сиделка» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган квалификацияле персоналның булуын раслый торган, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан декларацияләнгән белешмәләр;

к) оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документларның оешма җитәкчесе тарафыннан расланган һәм мөһер (булганда) сугылган күчермәләре;

л) оешма, индивидуаль эшмәкәрнең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә оешма, индивидуаль эшмәкәрнең массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә аларның булмавы турында белешмә кәгазе (әлеге исемлекләрдән өземтәләрне теркәп).

Оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан әлеге пунктның «а», «г», «е», «ж» пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин